# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА ХАС МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР: ИКЕНЧЕ ЭЧТӘЛЕК ТУДЫРУ

**Дания Фатыйх кызы Заһидуллина,**
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,
Россия, 420111, Казан, Бауман ур., 20,
zagik63@mail.ru

Дөнья әдәби барышында бербөтен итеп карала торган милли әдәбиятлар, үз чиратында, гаять үзенчәлекле сыйфатларга ия булалар. Һәр милли мәдәнияткә хас традицияләр аерым милләтләрнең дөньяга карашы, менталитеты, психологик халәте турында күзаллау хасил итә. Шуңа күрә дә әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм формасындагы милли аерымлыкларны өйрәнү мөһим. Әдәбияттагы читләтеп әйтү алымнары, бигрәк тә татар әдәбиятындагы «икенче эчтәлек тудыру» шундыйлардан. Татар әдәби барышында үсеп-үзгәреп, әлеге күренеш «эзоп теле» әдәби алымына әверелә.

Урта гасырлар төрки-татар әдәби текстларындагы «яшерелгән» мәгънә әдәбиятта дини дөнья сурәтен тудыру белән бәйле була. Бигрәк тә суфи әдәбияттагы кешенең Илаһи белән кушылырга омтылышы «икенче» эчтәлек барлыкка китерә. Суфичыл символларга яшерелгән әлеге «икенче» эчтәлек, асылда әдәби әсәрнең төп эчтәлеге буларак, яшәеш нигезләре хакында дини күзаллау булдыра.

XX йөз башында дөньяви әдәбият формалашу бу күренешнең үзгәрүенә сәбәп була. Суфичыл символлар, дини эчтәлекне югалтып, дөньяви мәгънәләр белдерә башлый. Алар ярдәмендә яшәешкә фәлсәфи бәя бирелә.

1917 елдан соң татар әдәбиятындагы бу күренеш активлыгын югалта. Ләкин «икенче эчтәлек тудыру» традициясе Г.Кутуйның гражданлык лирикасында кабат барлыкка килә. Автор позициясе һәм лирик герой позициясе арасындагы каршылык «яшерелгән мәгънәгә» ишарә ясый. Белеме буенча филолог, эстет һәм интеллектуал Г.Кутуй 1920 еллар шигъриятендә үзенчәлекле лирик герой – «массалар вәкиле», үткәннең барлык кыйммәтләрен кире кагучы нигилист образы тудыра. Үзен тәрбияләп үстергән абыйсын үтерүче, яки узган чорлар мәдәниятеннән баш тартучы лирик герой чор символына әверелә. Әлеге мәдәният тибына хас читләтеп әйтүләр системасы төрле сыйфаттагы әдәбилек модусларын белдерергә мөмкинлек бирә. Икенче эчтәлектә трагик пафос – ирония белән кушыла һәм дөньяга экзистенциаль караш белдерергә ярдәм итә.

1960 елларда Г.Афзал иҗатында әлеге күренеш тулы канлы «эзоп теле» алымына үсеп җитә. Шагыйрь милли әдәбият өчен өр-яңа кеше концепциясе белән чыгыш ясый: куркак, мескен, икейөзле кешене тоталитар режим җимеше дип тәкъдим итә.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, милли мәдәни традиция, әдәби алым, икенче эчтәлек тудыру, «эзоп теле», символ, лирик герой.

Һәр милли әдәбият, бер яктан, дөнья әдәбияты дигән зур иҗат процессының аерылгысыз өлешен тәшкил итә, икенче яктан, шушы барышта үз юлын, сукмагын табарга омтыла. «Теләсә кайсы аерым алынган мәдәнияттә, аның бөтен барышында яки күпмедер тарихи аралыгында, стадиаль бөтенлекләрдән өстә аерым бер кыйммәтләр чылбыры күзәтелә, аны милли мәдәни традиция дип атарга мөмкин. Милли мәдәниятләр үз үсеш юлларында бер-берсе белән «мәдәният булу» ягыннан тәңгәлләшә дә, шул бөтенлекнең өлешләре сыйфатында үз-үзләрен, үз үзенчәлекләрен барлыкка китерә, ягъни үзләрендә өстәмә, секундар тәртипләү тудыра, ул исә примар, фундаменталь диахроник тәртипләүдән өстә тора (һәм, табигый, соңгысын каплый да)» [1: 12-13]. Шуңа күрә дә милли әдәбиятның үзенчәлекләрен табу, аның тирәннән килгән үз, уникаль традицияләрен, үз эчке үсеш законнарын барлау, И.Смирнов әйткән «секундар системаның» аерым элементларын ачыклау омтылышы гаять актуаль. Чөнки милли мәдәни традиция милләтнең үзаңы, дөньяга карашы, психологик рәсеме хакында күзаллау бирә.

Мәкаләдә без татар әдәбиятына хас үзенчәлекле бер күренеш – әдәби әсәр текстында икенче эчтәлек тудыру, шуның, үзгәреп-трансформацияләнеп, «эзоп теле» алымына әйләнүе хакында сүз алып барырбыз. Ләкин төп мәсьәләгә керешкәнче, кайбер нәзари төшенчәләрне ачыклап китү сорала.

XX гасырның урталарыннан «мәгълүмат җиткерү чарасы» [2: 29] буларак өйрәнелә башлаган әдәби әсәр текстында эчке мәгънә катламының (подтекст) барлыгы дөнья әдәбияты өчен гадәти, закончалыклы күренешләрдән санала. Бүгенге фән аның барлыкка килүен иҗатчының аң төпкелендә формалашкан, аң тупсасын узып чыга алмый торган караш-мөнәсәбәтләр үзенчәлегенә бәйли [3: 71-79]. Шуңа күрә дә фәндә «сүзләргә яшерелгән мәгънә» (Лурия), «өстәмә мәгънә» (И.Р.Гальперин), «импликация» (И.В.Арнольд һ.б.), «эчке мәгънә» (Р.Барт) кебек күпсанлы шәрехләүләр яшәп килә. Аларны берләштерә, «подтекст» төшенчәсенең асылын белдерә торган билгеләмә, безнең карашыбызча, В.В.Виноградов тарафыннан тәкъдим ителә. Галим аны «текстның потенциаль семантикасы» [4: 81] дип атый.

Теләсә кайсы милли әдәбиятта, теләсә кайсы әдәби текстта эчке мәгънә катламының булуын таныган хәлдә, без милли әдәбияттагы үзенчәлекле «икенче эчтәлек», «яшерелгән эчтәлек» төшенчәсенә мөрәҗәгать итәбез. Эчке мәгънә, подтексттан аермалы буларак, аңлы рәвештә тудырыла, кайбер очракларда сюжет яки сурәт ярдәмендә барлыкка китерелгән «беренче эчтәлек»тән алгарак чыга, мөһимрәк роль уйный башлый. Шулай итеп, икенче эчтәлек – иҗатчы тарафыннан махсус чаралар ярдәмендә әсәрнең төп эчтәлегенә янәшә тудырылган, үзенең мәгънәсе белән аннан кискен аерылып торган һәм киңрәк, гомумирәк, абстракт-кыйммәти бәя бирүгә йөз тоткан мәгълүматый катлам. Әдәби текстта аның булуы мәҗбүри түгел. Ләкин икенче эчтәлек хасил булу – иҗатчының һәм милли әдәбиятның югары сәнгати үсеш дәрәҗәсенә ирешүе хакында сөйләсә, аның нинди чаралар ярдәмендә тудырылуы милли сүз сәнгатенең үзенчәлеге дип билгеләнә ала.

Гадәттә, әдәбияттагы ниндидер күренеш аерым бер үсеш-үзгәреш этабында күзгә бәрелеп тора башлый, ул тикшеренүчене кабат тарихка әйләнеп кайтып, аның формалашу юлын күзәтергә этәрә. Әйтик, XX йөз башы һәм 1960–1980 еллар татар авангард әдәбиятына хас билгеләрдән, эчтәлекнең күпкатлылыгын, барлык мәгънәләрне табып бетерә алмау тойгысы уятуын, автор тарафыннан махсус яшерелгән фикерләр эзләү омтылышы тудыруын күрсәтергә кирәк. Аның тамырларын эзләү исә урта гасырлар татар әдәбиятына юл күрсәтә.

Урта гасырлар татар әдәбияты шәрык-мөселман әдәбиятларының аерылгысыз өлеше булып күзаллана. Һәр иҗатчы – мөселман, һәм әдәбиятта тудырылган дөнья сурәтенең бары тик бер модельгә: Алла һәм кеше моделенә – корылуын исәпкә алганда, урта гасырлар әдәбиятында бербөтен яшәешнең аерылгысыз өлеше булган кеше тормышы илаһи кануннар фонында бәяләнү аңлашыла. Мондый катлаулы психологик, рухи процесслар әдәбиятны читләтеп әйтү, сер томанына төрү, символлар теленә мөрәҗәгать итү кебек алымнар эзләргә мәҗбүр итә. Галимнәр яшерен эчтәлек белән уйнауның гомумән шәркый фикерләү рәвешенә хас сыйфат булуын да искәртәләр [5: 308]. Бигрәк тә суфи әдәбиятта, кешенең илаһи мәхәббәте, Аллага якынаюы турында сөйләгәндә, суфичыл символлар икенче эчтәлек тудыруда катнаша, аларның бер, төп мәгънәсе шул эчтәлекне шәрехләргә юл күрсәтә. Бу үзенчәлеккә әле Е.Э.Бертельс игътибар иткән була. Аның фикеренчә, суфи әдәбиятта парлы символлар мөселман дөнья сурәтен һәм кеше кичерешләренең үзгәрешен тергезүгә хезмәт итә [6: 111].

Әйтик, Казан ханлыгы чорының күренекле шагыйре Кол Шәрифнең «Башың күтәр гафләтдин…» шигыре лирик геройның зикер әйтү процессын сурәтли (беренче эчтәлек). Һәр тезмә «һу дигел» рефрены белән тәгәлләнә. Үз-үзенә мөрәҗәгать итеп, Кол Шәриф зикер әйтергә өнди [7: 25].

Шигырьдә ике сызык янәшә бара: бер яктан, кешенең үз-үзе белән сөйләшүе аша зикер әйтүнең мөһимлеге раслана, икенче яктан, башкаларга (укучыга, мөселманнарга) аның ни өчен кирәк булуы искәртелә. Бу вакытта шагыйрь традицион суфи символларга мөрәҗәгать итә: бәхер (энҗе) – гаувас (чумучы) пары илаһи гыйлемгә омтылучы суфины белдерә. Традицион образлар: гарше шаһи (күкнең тугызынчы каты) һәм гашыйк – ярдәмендә хакыйкатькә омтылу рәсеме тудырыла. Зикер аша хакыйкатькә төшенүчене автор «һу кошы» дип атый. Йокламыйча, күз яшьләре түгеп зикер әйтүче яна-яна канатлы булган кошка тиңләштерелә. Шулай шартлы-символик катлам аркылы шигырь суфичыл дөнья сурәтен тергезә. Бу сурәттә кешенең урыны – Илаһига якынаю юлларын эзләү булса, шул юлларның берсе зикер аны чыннан да күккә күтәрә, канатлы кош кебек югарыга менү, Аллага якынаю мөмкинлеге бирә. Икенче эчтәлек зикер әйтеп утыручы лирик геройны

сурәтләгән чынбарлыктан – дини-символик дөньяга күчә.

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъярның «Нәсыйхәт» шигырендә дөнья сурәте шулай ук парлы гөл-былбыл (Илаһи һәм кеше) һәм җир тормышын символлаштырган баг, бакча (җир тормышы мәгънәсендә), кешедәге тискәре сыйфатларны, тормыштагы явызлыкны аңлаткан тикән (тигәнәк) символлары аша җиткерелә [8: 165]. Былбыл яки гамил (егет) бакчада тигәнәк үскәнгә борчыла. Ләкин бер көнне чәчәкне күрә, аңа гашыйк була һәм сорый: бакчада тигәнәк нигә кирәк? Шулай шагыйрь тормышта явызлык күп булуны искәртә. Кешегә мөрәҗәгать итеп — явыз булмаска («Гөле сач ул багыңа, булма җаһил») чакыра. Әгәр һәр кеше гашыйклык юлына чыкса, җир «гөлстан»га әверелер иде дип белдерә. Шагыйрь тормышны камилләштерү хакында сөйли. Җир тормышы һәм яшәеш моделе ике мөстәкыйль эчтәлек рәвешен ала.

Урта гасырлар әдәбиятында формалашкан әлеге сыйфат (символларның икенче эчтәлек хасил итүе) XX йөз башы яңарыш әдәбиятында традиция буларак файдаланыла. Дөньяви әдәбият көчле бер дулкын булып мәйданга чыкса да, суфи символлар милли әдәбиятта үзенең урынын саклый: алар иҗатчыларга эчтәлекне тирәнәйтү, әсәрләрне серле, күпмәгънәле ясау өчен кулай булып тоела. Шул ук вакытта дини символларның эчтәлегендә дөньяви мәгънә алга чыга һәм фәлсәфи фикер белдерүгә хезмәт итә. XX йөз башында язылган әсәрләрнең зур күпчелеге шушы сыйфаты белән үзенчәлекле.

Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә...» (1913) хикәясен мисал итеп алсак, әсәр мәхәббәтнең югалуына, үлемгә, яшь гомерне үлем белән төгәлли торган яшәешкә ләгънәт укып язылган. Ул хикәяләүченең «хәрабә» — яшьлек, матурлык, мәхәббәт, байлык, тәртип җимерекләре белән очрашу мизгелен тергезә. Шушы мизгелдә кешенең өметләр белән яшәүче яртысы үлем котылгысызлыгын аңлаган икенче яртысы белән кушыла, хакыйкатькә төшенә [9: 149-156]. Хикәядә «хәрабә» символының суфичыл мәгънәсе – иманын югалткан кеше күңелен аңлатуы – арткы планга чигенә. Аның урынын дөньяви мәгънәләр ала һәм тормыш-яшәешкә ләгънәт укучы сызлану фәлсәфәсен белдерә башлый.

Шулай итеп, күп гасырлар дәвамында үсә-үзгәрә килеп, татар әдәбиятында икенче эчтәлек тудыру традицияләре урнаша. Яшерен эчтәлек символлар ярдәмендә хасил була. Дини-суфичыл әдәбиятта символлар тудырган эчтәлек, дини дөнья сурәте хасил итеп, беренче урынга чыкса, XX йөз башының дөньяви әдәбиятында исә фәлсәфи эчтәлек барлыкка китерә, һәм икенче планда урнаша. Бу күренеш татар әдәбиятында символизмның тиз һәм көчле формалашуына китерә.

1917 елдан соң татар әдәбиятының, революция дулкынына эләккән күп әдәбиятлар кебек үк, бик зур үзгәрешләргә дучар булуы мәгълүм. Болар әдәби әсәрләрнең тематикасы-проблематикасы яки геройлар системасына, жанрларга гына кагылмыйча, әдәби-эстетик алымнарда да күзәтелә. Шул исәптән, героик-революцион әсәрләр дулкынында «күмелеп калган» яшерен эчтәлек тудыру, читләтеп әйтү кабат татар әдәбиятына әйләнеп кайта. Ләкин ул бөтенләй башка механизмнарга, үзгә язу техникасына таяна башлый.

Әлеге үзгәрешнең беренче чагылышы Гадел Кутуйның автор үзе футуристик шигырьләр тупланмасы буларак тәкъдим иткән «Көннәр йөгергәндә» (1924) китабында һәм 1922 еллардан башлап вакытлы матбугатта күренгән әсәрләрдә аермачык. Аларда автор карашы белән каршылык халәтендәге нигилист лирик герой образы тудырыла. Автор позициясе – бер, ә герой позициясе – икенче эчтәлек хасил итә. Автор илдә барган инкыйлаби үзгәрешләрне ирония һәм кире кагу ноктасыннан бәяли. Герой исә – шушы үзгәрешләр баласы, яңа тормыш төзүче. Һәр шигырь әлеге «яңа герой»ны ниндидер аерым бер сыйфаты белән күрсәтә.

Берничә мисал китерик. Җыентыкка исем биргән шигырь – «Көннәр йөгергәндә», аның лирик герое барлык «иске»лекне кире кага, хәтта ата-анасына, аларның үлеменә хөрмәт белән карауны да искелек калдыгы буларак карый:

*Анам үлде.*
*Үлгән чакта мин юк идем,*
*– Яшә, улым, –*
*Димәде.*
*Димәсә ... ни?*
*Кимәсәм... ни?*
*Чәнчелсеннәр*
*(Фатыймалар һәм Һавасы)*
*Барысы бергә иске кешеләр!* [10: 5].

Әлеге герой үз нәсел-нәсәбеннән һәм ата-анасыннан баш тарта, заводларда эшләүчеләрне ата-анасы урынына куя. Бу сүзләр яңа тормыш

төзүче яшь буынның аңында гомумкешелек кыйммәтләренең капма-каршысына алмашынганлыгын белдереп килә.

Тагын бер мисал – эпик детальләр белән баетылган «Сәрвәр-давыл» шигыре. Лирик герой горурланып һәм яратып 1919 елдан комсомолда, Гражданнар сугышы батыры, Чапаев отрядының комвзводы Сәрвәр хакында сөйли, аны «яңа кешеләрнең» берсе кебек тәкъдим итә. Ләкин шигырьнең башлам өлешендә лирик геройның үзенә кагылышлы кисәк бар. Комсомолга кергән өчен өйдән үзен куып чыгарган Әхнәф абзасына кул күтәрә ул:

*Чыктым, ләкин ул егылды*
*Гражданнар сугышында.*
*«Дошман, бет!»*
*Дип,*
*Приклад белән берне*
*Аның*
*Яңак төбенә*
*Тамыздым!*
*Искелеккә - төкер!*
*Барыбер бит*
*Әхнәфләргә чокыр*! [10: 11].

Шулай шигырь Гражданнар сугышы чорында үз туганын, үзен үстергән кешене үтерергә җөрьәт иткән яшь кеше образын тудыра. Трагик пафос бу адымның шулай булырга тиеш кебек кабул ителүеннән килеп чыга: «яңа кешеләр», туганлык мөнәсәбәтләренә дә карап тормыйча, «искелекне» юк итәләр!

«Җан сатам» шигырендә тудырылган сурәт тагын да фаҗигалерәк тоела. Шагыйрь яңа тормышны татар, инглиз, чуаш, яһүд һ.б. «җаннарны» лирик герой сата торган базар кебек күзаллый. Соңгы юллар аеруча символик яңгыраш ала:

*Җан сатам,*
*Бер сугуда синеке була,*
*Мирас булмас,*
*Юк итәм*... [10: 14].

Шигырьдә пародия алга чыга, ул шагыйрьнең узган мирасны яклаучылар белән теләктәш икәнлеген ассызыклый. «Җан сату» аллюзиясе дөнья әдәбиятыннан мәгълүм сюжетлар белән ассоциация уята, бу сурәтләнгән картинаның фаҗигалелеген көчәйтү өчен кирәк. Мирас сату һәм җан сатуның янәшәлеге милләт өчен мирасның кеше өчен җан кебек кадерле булуына ишарә ясый. Әдәбият белгече Г.Кутуй, күрәсең, илдә бара торган хәлләрне бәяләү юлын икенче эчтәлек тудыруда таба.

Ирониялe эчтәлек Г. Кутуйның иҗат эшенә багышланган шигырьләрендә дә алга чыга. Әйтик, «Эшче шагыйрь» шигыренең лирик герое иҗат эше белән күңел кушканга яки «уй ташканга» түгел, бәлки башкалар язганга шөгыльләнә. Тагын бер шигырь – «Татар шагыйрьләренең кулак базына» – башланган сөйләшүне дәвам итә. Лирик герой халык җырларының үзе өчен «тар», борынгы поэмаларның – «файдасыз» булуын ассызыклый һ.б.

Шулай итеп, Гадел Кутуйның 1920 еллар уртасы иҗатында совет идеологиясе алып килгән тискәре яңалыкларны, аның кеше психологиясенә коточкыч йогынтысын күрсәткән шигырьләр бар. Алар татар әдәбияты өчен традицион яшерен эчтәлек тудыру, читләтеп әйтү юлы белән язылганнар. Ләкин бу вакытта икенче эчтәлек символлар аша түгел, шигырьдәге автор һәм лирик герой позициясе арасында туган киеренкелек нәтиҗәсендә хасил була. Шулай итеп, 1917 елдан соң без сүз алып бара торган традиция тамырдан үзгәреш кичерә.

Алга таба күп кенә татар шагыйрьләренең (Х.Туфан, К.Нәҗми, Ә.Фәйзи һ.б.) аерым бер шигырьләрендә читләтеп әйтүгә мөрәҗәгать итү күзәтелә. Ләкин күренеш озак вакытлар «көч җыю» халәтендә кала, киңәеп китә алмый. Бары тик 1960 елларда, татар әдәбияты «җепшеклекнең» шифалы тәэсирендә милли нигезләргә кайту юлларын барлый башлаган бер вакытта, кабат әдәби процесста мөһим урын ала. Моның «сәбәпчесе» – шагыйрь Гамил Афзал гражданлык лирикасы белән сатирик шигъри ят чикләрендә үз синкретик язу рәвешен тудыра, «яшерен эчтәлек»не тулы канлы эзоп теле алымына үстереп җиткерә.

Гамил Афзалның 1960–1980 еллар поэзиясендә моңа кадәр бер шагыйрь иҗатында да күренмәгән кеше концепциясе пәйда була. Лирик «мин», герой – куркак, юаш, күңелендә зур омтылышлар ятса да, аларны «тышка чыгарырга» кыюлыгы җитмәгән гади кеше. Шигырьдән-шигырьгә кабатланып, ул замана баласы, совет идеологиясе тудырган кеше тибы кебек кабул ителә башлый. Үз позициясен барлык ваклыкларында сөйләүче әлеге герой автор ирониясе һәм экзистенциясе белән киеренкелеккә, каршылыкка керә: бу каршылык яшерелгән, әйтелмәгән автор фикерен ачыклау юлын укучыга күрсәтә. Нәтиҗәдә барлык шигырьләр өчен уртак яшерен эчтәлек – кешедән куркак, битараф, кол

ясаган идеологиягә карата яшь аралаш көлү, сызлану мөнәсәбәте хасил була.

«Мин» исеменнән сөйләүче гади кеше образын шагыйрь 1950 еллардан формалаштыра башлый. Әйтик, «Гадел эшкә сәбәп» (1955) шигырендә хатыны белән аерылышканнан соң аның туган-тумачасын эштән куган, «гаделлек урнаштырган» МТС башлыгы шундыйлардан. «Кыяр-кыймас» (1956) шигырендә сөюен әйтергә җөрьәт итмичә, яраткан кызының башка егеткә кияүгә киткәнен «карап калган» куркак, оялчан егет сурәте пәйда була. Ул, хәтта, кайгысын да «кыяр-кыймас» кына кичерә. Мактанчык карт («Сәләхетдин бабай сүзләре», 1956), үз эшлексезлегендә башкаларны гаепләүче механик («Механик кемне сүгә», 1956), эчкече бригадир («Тотып җибәр, апаем...», 1956), сүздә батыр колхоз председателе («Җыелыштан соң уйлану», 1956), эгоист җитәкче («Их, бар иде түрә чаклар...», 1956 һ.б.), күпкә өмет иткән егет («Карт егет хәле», 1956), күзбуяучы җитәкче («Ревизор көткәндә», 1956; «Эшеннән азат ителгән бюрократ зары», 1957 һ.б.), карак («Шәрифулла күршем белән», 1956 һ.б.), надан («Шундый лектор да була», 1956), ялкау («Кайгырмасов хикәясе», 1956) һ.б. образлар галереясы шагыйрьгә, бер яктан, тормыштагы бик күп кимчелекләрне кире кагу объекты ясарга мөмкинлек бирә. Икенче яктан, әлеге беренче заттан сөйләүче типлар урынын лирик герой яулый бара. Г.Афзал әлеге героен тормыш-көнитешнең төрле ситуацияләренә куя, аны төрле яклап күрсәтә башлый.

Г.Афзал сатирасының иң билгеле әсәрләреннән, «Мыек борам» (1958) шигыре, әйтик, тормыштагы һәр кимчелекне, җитешсезлекне күрүче, ләкин аны бетерү, хаксызлыкны – туктату урынына, «гайрәт белән мыек боручы» геройның яшәү фәлсәфәсен куркаклык буларак аңлата:

*Иртә-кичен һәр урамда*
*Эчеп йөргән хулиганга*
*Бирер идем каты җәза,*
***Килеп чыгар бәла-каза;***
*Тешне кысып карап торам,*
*Гайрәт белән мыек борам* [11: 180].

«Шайтан» (1958) шигырендә ялкау («*Шайтан әйтә безнең ишегә: / – Ял ит, әйдә, төкер эшенә!*»), комсыз («*Явыз шайтан килеп шом сала:/ –Хәерче дә синнән күп ала...*»), эчкече, көнче герой үзенең әлеге сыйфатларын шайтан котыртуы дип бәяли!

«Елмаям уйчан гына...» (1968) шигырендә дә шагыйрь әлеге геройны – тормышта матурлыкка яки хаксызлыкка очраганда да битарафлык битлеге киеп, елмаеп яшәүче кеше сурәтен – үз исеменнән ясап куя. Әлеге кеше берчакта да үз фикерен белдерми, эчтән әйләнә-тирәсендәге хәлләргә каршы төшсә дә, аның сүз әйтергә кыюлыгы җитми. Ул «Мыек борам» шигыренең лирик героен хәтерләтә.

Тагын бер шигырендә бу күренешне шагыйрь әсәр исеменә чыгара – «Тун астында кыюлык» дип исемли (1969). Озын шигырь әлеге куркак кеше психологиясен шактый тулы ача: бер яктан, күңел зур эшләргә ашкынып тора, ләкин аларга тотынырга кыюлык җитми! Алга таба геройның «нидән» куркып торганы да билгеле була: җыелышларда дөреслекне әйтер иде – квартира аласы бар; премиядән коры калу куркынычы да кыюлыкны юкка чыгара; тәнкыйтьләсәң – эштән җибәрерләр дип тә уйлый һ.б. Шул рәвешле, асылда автор кешене куркырга «өйрәткән» система турында сөйли. Аның герое исә: «*Пенсиягә чыккач, Алла бирсә / Алга таба кыю барырмын,/ Тыныч күңел белән тыныч кесә, / Дөреслекне ярып салырмын*» [11: 205] – дип юана. «Үз туксаным туксан» (1971) шигырендә герой, хәтта, лоторейга машина отарга да курка. Бу шигырьдә автор героен «яшәүдән курку» чигенә китереп җиткерә:

*Дөрес яшимме дип шүрләп куям,*
*Эчтә шөбһә туа;*
*Мин куркытып-кырып дөнья куам,*
*Курку мине куа* [11: 210].

Бер үк вакытта әлеге куркак герой һәр шигырьдә үз-үзен югары куючы кебек ачыла бара. Әлеге характер куркаклык һәм эгоистлыкның берлеге рәвешен ала:

*Күңел ята тук сыердай пошмас,*
*Кибәк-фәлән иснәп пошкыра...*
*Ми сырына кысылып, төшәр-төшмәс,*
*«Мин шәп» дигән бөек сүз тора* [12: 118].

«Гомер китабы» (1969) шигырендә шагыйрь әлеге геройның 20 яшьтән 100 яшькә кадәрге «биографиясен» тергезә. Кырыкта да, алтмышта да, сиксәндә дә герой зур омтылышлар белән яши, ләкин аларны тормышка ашыра алмый. Инде йөзгә җиткәч, «Бер теләгем үтәлмәде» дип үкенә. Чөнки бу омтылышлар «тун астында» калган, ахыр чиктә, кеше гомере нидер көтеп узган булып чыга.

Шул рәвешле, шагыйрь идеология күрергә теләгән идеал кеше – куркак кеше образын

барлыкка китерә. Шигырьдән-шигырьгә шушы ялган фәлсәфәне ача бара. «..Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә» шигырендә, әйтик, «*Гомер буе билдән пычрак ерып,/ Ап-ак көе калды намусым*» дигән юллар укучыны әлеге фәлсәфәгә ышанмаска чакыра. Яки «Чабаклар йөзгән Иделдә» шигырендә «*Арыслан ята күңелдә, / Кулымда куяным бар...*» тезмәләре әлеге геройның юанычы булып яңгырый. Шагыйрь әлеге героен шул исемдәге шигырендә «сак кеше» дип атый («Сак кеше», 1971). Аның характерын усал һәм юаш «ике мин»не берләштереп яшәү буларак бәяли («Ике мин», 1972).

Гамил Афзал бу күренешнең сәбәпләре хакында да уйлана. Ул аны үткәнне каралтып, киләчәк белән яшәргә өйрәтүдә таба («...Безнең алда апа, кара такта», 1973). Лирик геройның «*Үткән заманнарны сүгә-сүгә, / Безнең инде чәчләр агарды*» дигән сүзләре совет идеологиясе тудырган буыннар фәлсәфәсе булып яңгырый. Бу фәлсәфә авторда сызлану уята. Шагыйрь кулланган «эзоп теле» алымы исә татар шигърияten үзгәртерлек көч белән яңгырый.

Г.Афзал башлаган сөйләшү 1960–1980 еллар татар шигъриятендә гражданлык лирикасы чикләрендә кинәт үсеп китә. «Р.Фәйзуллиннар буыны» дип исем алган шагыйрьләр иҗатында эзоп теле, икенче эчтәлек тудыру алымнары татар шигърияten тамырдан үзгәртерлек яңалык булып яңгырый, поэзиянең актуальлеген, әдәби төрләр арасында беренчелеген тәэмин итә, кысрынкы шартларда иҗтимагый-сәяси позицияне шактый ачык һәм кыю белдерергә мөмкинлек бирә.

Әдәби әсәр текстында икенче эчтәлек тудыру, татар әдәбиятына хас үзенчәлекле бер күренеш буларак, урта гасырларда, дини-суфичыл әдәбият чикләрендә формалаша башлый. Ләкин дөньяви, милли әдәбият бу традицияне кире какмый, киресенчә, XX йөз башының әдәби күтәрелешендә ул текстларның эчтәлеген тирәнәйтү чарасына әверелә. 1917 елдан соңгы үзгәрешләр исә әдәби күренешнең «эзоп теле» алымына әйләнүен тәэмин итә. Күрәсең, милли әдәбиятыбызга хас әлеге читләтеп әйтүләр системасы татар әдәбиятындагы синтетизм күренешенә, текстлардагы күпкатламлылыкка барып тоташа. Әлеге форма үзенчәлекләре, үз чиратында, милли иҗади аңның ассоциативлыкка, яшерен өстәмә мәгънәләр тудыруга омтылышы турында сөйли.

**Әдәбият**


1. *Смирнов И.* Мегаистория: к исторической типологии культуры. М.: «Аграф», 2000. 544 с.
2. *Лотман Ю.М.* Лекции по структуральной поэтике // Ю.М.Лотман и тартуско-московская семиотическая школа. М.: Гнозис, 1994. С.10–257.
3. *Голякова Л.А.* Текст. Контекст. Подтекст. Пермь, 2002. 232 с.
4. *Виноградов В.В.* О языке художественной прозы. М.: Наука, 1980. 360 с.
5. *Смирнов А.В.* Номинативность и содержательность: почему некритическое исследование «универсалий культуры» грозит заблуждением? // Универсалии восточных культур. М.: «Восточная литература» РАН, 2001. С.290–317.
6. *Бертельс Е.Э.* Избранные труды. Т.3: Суфизм и суфийская литература. М., 1965. 527 с.
7. Кол Шәриф һәм аның заманы / Төз. һәм фәнни. ред. М.Әхмәтҗанов, Ә.Хәсәнов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 237 б.
8. Татар поэзиясе антологиясе: беренче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 512 б.
9. *Әмирхан Ф.* Әсәрләр: 4 томда: 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 478 б.
10. *Кутуй Г.* Көннәр йөгергәндә. Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1925. 56 б.
11. *Афзал Г.* Сайланма әсәрләр: 3 томда: 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 383 б.
12. *Афзал Г.* Айлы кичләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 336 б.